**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
ЧЕРЕМШАНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 сентябрь 2023 ел **Чирмешән авылы** № 263

Муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге № 248-ФЗ Федераль законның 28 статьясындагы 3 өлешенә ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен куелган квалификация таләпләрен расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати - телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Башкарма комитет
җитәкчесе И.М.Җамалетдинов

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Башкарма комитеты карарына
кушымта
29.09.2023 № 263

# Муниципаль контрольне гамәлгә ашырырга вәкаләтле муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре

## Гомуми нигезләмәләр

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы территориясендә муниципаль җир контролен, муниципаль торак контролен гамәлгә ашырырга вәкаләтле муниципаль учреждениеләрдә инспектор вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре һәм Инспектор вазыйфаи бурычларын башкару өчен кирәкле һөнәри белем дәрәҗәсенә, белгечлек буенча эш стажына, әзерлек юнәлешенә, белемнәренә һәм күнекмәләренә таләпләрне билгели.

Әлеге Квалификация таләпләре муниципаль хезмәткә караган Инспектор вазыйфаларын биләүче затларга кагылмый.

## I. Һөнәри белем дәрәҗәсенә таләпләр

Инспектор вазифасын биләү өчен физик затның булырга тиеш:
югары белем - бакалавриат;
югары белем - специалитет, магистратура;
югары белем - югары квалификацияле кадрлар әзерләү.

## II. Белгечлек буенча эш стажына таләпләр

Эш стажына таләпләр куелмый.

## III. Вазифа бурычларын үтәү өчен кирәкле белем һәм күнекмәләргә таләпләр

1. Инспектор вазифасын биләү өчен физик зат вазифа бурычларын үтәү өчен кирәкле түбәндәге белемнәргә ия булырга тиеш:

Россия Федерациясенең дәүләт теле;

Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль, коррупциягә каршы тору, административ хокук бозулар турында законнар, муниципаль контрольнең тиешле предметларындагы законнар нигезләре;

Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, дәүләт тармак стандартлары һәм муниципаль контроль предметына кагылышлы мәсьәләләр буенча башка норматив-техник документлар;

мәгълүмати-коммуникацион технологияләр өлкәсендә, шул исәптән аппарат һәм программа тәэминаты белемнәрен, дәүләт учреждениеләрендә заманча

мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне куллану мөмкинлекләрен һәм үзенчәлекләрен кертеп, шул исәптән ведомствоара документлар әйләнеше мөмкинлекләрен, мәгълүмати куркынычсызлыкны тәэмин итү өлкәсендәге гомуми мәсьәләләрне куллану.

2. Инспектор вазифасын биләү өчен физик зат вазифа бурычларын үтәү өчен кирәкле түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиеш:

төрле мәгълүмат чыганаклары белән эшләү һәм бу мәгълүматны муниципаль контроль функцияләрен гамәлгә ашыру буенча бурычларны хәл итү өчен куллану сәләте;

белемнәрне гамәли эшчәнлек өчен нигез буларак муниципаль контрольнең тиешле предметларында куллану;

мәгълүмат материалын системалаштыру, структуралаштыру һәм анализлау һәм бу материалны төрле эшчәнлеккә бүлү сәләте;

контроль (күзәтчелек) чараларының үтәлеше турында исәп-хисап документациясен алып бару;

компьютерның эчке һәм периферия җайланмалары белән эшләү

мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре, шул исәптән «Интернет» челтәре белән эшләү;

операцион системаларда эшләү;

текст редакторларында эшләү;

электрон таблицалар белән эшләү;

электрон документларда график объектларны куллану;

муниципаль контроль функцияләрен гамәлгә ашыру буенча бурычларны хәл итү өчен мәгълүмати системаларда эшләү.